ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МАКЫЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

13.11.2019 с. Русское Макулово 04

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Сеитово авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 3 декабрендә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Сеитово авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Сеитово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы:

**- Сеитово авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау**

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Сеитово авылы, Үзәк урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасында10.00 сәгатьтә уздырырга.
4. Халык җыенын оештыручы итеп Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Макыл авыл җирлеге**
**Башлыгы** **А.И. Матвеева**